# КАРАР

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге составына керүче Таллы Күл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2022 нче елның 28нчы ноябрь № 3

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «2023 елда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Яңа Зареченск авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, 1 Төркем инвалидларыннан, 75тән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү дә керә:

- Таллы- Күл авылындагы юлларын тоту (кардан арындыру, үлән чабу);

-Таллы-Күл авылындагы урам утларына хезмәт күрсәтү (ремонт, урам утларын алыштыру).

«ӘЙЕ ЮК».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 121 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 68 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 62 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 6 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге составына керүче Таллы Күл торак пунктында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, 75тән өлкәнрәк яшьтәге ялгыз яшәүче 1нче Төркем инвалидларыннан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?:

- Таллы- Күл авылындагы юлларын тоту (кардан арындыру, үлән чабу);

-Таллы-Күл авылындагы урам утларына хезмәт күрсәтү (ремонт, урам утларын алыштыру).

3. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://www.pravo.tatarstan.ru) Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яна Зареченск авыл җирлеге башлыгы А.Р. Зәбирова